| СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**03 октябрь 2023 ел** Күгеш авылы **№145**

«Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2016 елның 16 апрелендәге 42 номерлы Күгеш авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Күгеш авыл җирлеге Советы мәгълүматларын һәм норматив-хокукый актларын актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советының «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2016 елның 16 апрелендәге 42 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (администрация бинасы) адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштырырга.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе:** **А. А. Гатауллин**